**Республика Татарстан**
**Совет Большенуркеевского сельского поселения Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге советы**

РЕШЕНИЕ
19.06.2024 ел

КАРАР
№ 91

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 79 статьясы һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 28_1 статьясы, Сарман муниципаль районының «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлегенең 2022 елның 14 февралендәге 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Положениегә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 6.1 пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән чорда ялган документлар һәм (яисә) аны бозган өчен муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлүен раслый торган, яисә документларның һәм (яисә) белешмәләрнең, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәве турында таныклый торган белешмәләрне тапшырганда;»

2) 9.3 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 N 594-ФЗ Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета;»;